КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 14 май г.Казань № 357

Элегрәк билгеләнгән даими йөртүләрнең муниципаль маршруты, даими йөртүләрнең муниципальара маршруты белән һәрберсенә ярашлы рәвештә ике һәм аннан да күбрәк уртак тукталыш пунктлары булган даими йөртүләрнең муниципаль маршрутын йә даими йөртүләрнең муниципальара маршрутын билгеләүне яки аларга үзгәреш кертүне килештерү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Элегрәк билгеләнгән даими йөртүләрнең муниципаль маршруты, даими йөртүләрнең муниципальара маршруты белән һәрберсенә ярашлы рәвештә ике һәм аннан да күбрәк уртак тукталыш пунктлары булган даими йөртүләрнең муниципаль маршрутын йә даими йөртүләрнең муниципальара маршрутын билгеләүне яки аларга үзгәреш кертүне килештерү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 14 май, 357 нче
карары белән расланды

Элегрәк билгеләнгән даими йөртүләрнең муниципаль маршруты, даими йөртүләрнең муниципальара маршруты белән һәрберсенә ярашлы рәвештә ике һәм аннан да күбрәк уртак тукталыш пунктлары булган даими йөртүләрнең муниципаль маршрутын йә даими йөртүләрнең муниципальара маршрутын билгеләүне яки үзгәртүне килештерү
тәртибе

1. Бу Тәртип «Россия Федерациясендә автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 13 июль, ФЗ-220 нче Федераль законның 13 статьясындагы 1 өлешнең 1.1 нче пунктына һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 13 июль, ФЗ-220 нче Федераль законны тормышка ашыру турында» 26 декабрь, ТРЗ-107 нче Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 4.1 нче пунктка таянып эшләнде һәм элегрәк билгеләнгән даими йөртүләрнең муниципаль маршруты, даими йөртүләрнең муниципальара маршруты белән һәрберсенә ярашлы рәвештә ике һәм аннан да күбрәк уртак тукталыш пунктлары булган даими йөртүләрнең муниципаль маршрутын йә даими йөртүләрнең муниципальара маршрутын билгеләүне яки үзгәртүне килештерү (алга таба – килештерү) процедурасын билгели.

2. Килештерү Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) һәм компетенциясенә әлеге маршрутларны билгеләү кергән вәкаләтле җирле үзидарә органы (алга таба – җирле үзидарә органы) арасында гамәлгә ашырыла.

3. Элегрәк билгеләнгән даими йөртүләрнең муниципаль маршруты, даими йөртүләрнең муниципальара маршруты белән һәрберсенә ярашлы рәвештә ике һәм аннан да күбрәк уртак тукталыш пунктлары булган даими йөртүләрнең муниципаль маршрутларын, даими йөртүләрнең муниципальара маршрутларын (алга таба – даими йөртүләр маршруты) билгеләү яки үзгәртү процедурасы, җирле үзидарә органнарының норматив хокук актларына, Министрлыкның норматив хокук актына таянып, билгеләнгән даими йөртүләрнең муниципаль маршрутларын, даими йөртүләрнең муниципальара маршрутларын билгеләү, үзгәртү, бетерү тәртипләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Даими йөртүләр маршрутын билгеләгәндә яки үзгәрткәндә, җирле үзидарә органы, Министрлык (алга таба – килештерүче органнар) тарафыннан

килештерүче орган адресына даими йөртүләрнең билгеләнә яки үзгәртелә торган маршрутын килештерү турында хат җибәрелә.

5. Даими йөртүләрнең билгеләнә яки үзгәртелә торган маршрутын килештерү турында хат алганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә хат җибәргән орган адресына даими йөртүләр маршрутын билгеләүне яки үзгәртүне килештерүне яисә аларны килештерүдән баш тарту сәбәпләренең мотивлаштырылган нигезләмәсен җибәрә.

6. Бу Тәртипнең 5 нче пункты белән билгеләнгән вакыт эчендә килештерүче органнан җавап алынмаган очракта, даими йөртүләр маршруты килештерелгән дип санала.

---